Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль район Советы

**КАРАР № VII-4**

Балык Бистәсе штп 2026 елның 17 марты

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турында» 07.07.2022 №XXIII-6 карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарының югары профессионал идарә итү составын формалаштыру максатларында һәм Татарстан Республикасы Президентының "Татарстан Республикасы идарәче кадрлар резервын формалаштыру, әзерләү һәм куллану тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" 06.10.2014 №ПУ-968 Указын үтәү максатларында Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын формалаштыру тәртибе турында» 07.07.2022 №XXIII-6 карарына (25.05.2023 №XXXVIII-11 редакциясендә) т\бәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 1.2 пунктның 3 абзацында "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 06.10.2003 №131-ФЗ Федераль законның 37 статьясында» сүзләрен "Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 20.03.2025 №33-ФЗ Федераль законның 22 статьясында" сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2 абзац өстәргә:

"Конкурс комиссиясе Нигезләмәсе һәм аның персональ составы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башлыгы карары белән раслана.»;

1.3. II бүлекнең 2 абзацын тиешенчә 3 абзац дип санарга;

1.4. II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.1.5, 2.1.6, 2.1.7 пунктлар өстәргә:

«2.1.5. Муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органында үткәрелә торган конкурста катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр Комиссиягә гариза бирә.

2.1.6. Җирле үзидарәнең башка органында уздырыла торган конкурста

катнашырга теләк белдергән муниципаль хезмәткәр Комиссиягә гариза һәм тутырылган, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органының кадрлар хезмәте тарафыннан имзаланган һәм таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган форма буенча анкета тапшыра.

2.1.7. Тиешле документларның төп нөсхәләре дәгъвачы тарафыннан конкурс сайлап алуына килгәч шәхсән тапшырыла. Граждан биргән белешмәләрнең дөреслеге өстәмә рәвештә тикшерелергә мөмкин. Гариза кадрлар резервын формалаштыруга документларны теркәү журналында теркәлә. Гариза биргән гражданга документларны алуда исемлек һәм аларны алу датасы күрсәтелгән расписка бирелә.»;

1.5. 2.2 пунктында "Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советы аппаратының кадрлар секторы (алга таба-кадрлар секторы)" сүзләрен "кадрлар белән тәэмин итү һәм муниципаль хезмәт бүлеге (алга таба – кадрлар бүлеге)" сүзләренә алмаштырырга.;

1.6. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының җирле үзидарә органнарында идарәче кадрлар резервын булдыру буенча конкурс комиссиясе турында нигезләмәне һәм конкурс комиссиясе составын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәгеТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе, муниципаль милек һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Башлыгы Р.Р. Ислямов